СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 14 декабре № 33/5

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы (03.06.2020 № 45/4, 12.11.2020 № 3/6, 05.02.2021 № 6/4, 16.08.2021 № 11/3, 13.02.2023 № 25/1, 20.06.2023 № 29/6, 17.08.2023 № 30/3, 09.11.2023 № 32/5 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 6 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 пунктта** икенче җөмләне төшереп калдырырга;

**2) 17 нче пунктны** үз көчен югалткан дип танырга;

**3) 20 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки вазифаи затына барлык кирәкле документлар белән класс чинын бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров